| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ГОРОД БАВЛЫ» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.12.2020 Баулы шәһәре №152

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 7 августындагы 96 номерлы карары белән расланган Товарлар җитештерүче, эш башкаручы, хезмәт күрсәтүче юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы “Баулы шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2020 елның 7 августындагы 96 номерлы карары белән расланган Товарлар җитештерүче, эш башкаручы, хезмәт күрсәтүче юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, физик затларга субсидияләр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5нче “Муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе” бүлегендә:

5.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиеш дип табылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк, яисә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясында каралган оешма тарафыннан, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган хокук бозуларны кичекмәстән бетерү максатларындагы эш-гамәлләр турында мәгълүмат

бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә, һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт алу максатларында башкарырга кирәк булган гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

“Баулы шәһәре”
муниципаль берәмлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров